ГОСУДАРСТВЕННЫЙ
КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

___09.03.2023_____ Казан ш. № __52_______

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2014 елның 15 сентябрендәге 80 номерлы боерыгы белән расланган Мәгълүматтан файдаланучыга аның таләбе буенча Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында» федераль законга һәм «Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында» федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы федераль законны кабул итүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының «Мәгълүматтан файдаланучыга аның таләбе буенча Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында» 2014 елның 15 сентябрендәге 80 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2014 елның 22 декабрендәге 80 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Мәгълүматтан файдаланучыга аның таләбе буенча Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«4) рәсми сайт – «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында мәгълүматны үз эченә алган сайт.»;

2.11 пунктының сигезенче абзацында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә» сүзләрен «рәсми сайтта» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис С.Е.Иванов.